| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ<br>ПО ОХРАНЕ И<br>ИСПОЛЬЗОВАНИЮ<br>ОБЪЕКТОВ<br>ЖИВОТНОГО МИРА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ<br>ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ ҺӘМ<br>АЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ<br>ИДАРӘСЕ |

**Приказ** **Боерык**

«03» декабря 2014 года Казань № 190_-од

Дәүләт аучылык инспекторлары турында

25.01.2013 елдан № 29 "Федераль дәүләт аучылык тикшерүе турында"гы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән тәңгәл килеп, **б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендәге урындагы затларның ( дәүләт аучылык инспекторларын) куелган Исемлеген расларга.

2. Исемлектә күрсәтелгән урындагы затларга (дәүләт аучылык инспекторларына):

"Ау турында һәм аучылык байлыкларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым канун чыгара торган актларына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль канун белән, Россия Федерациясенең башка федераль кануннары белән һәм аларга тәңгәлләшеп кабул ителә торган башка норматив хокукый актлар, ә шулай ук Татарстан Республикасының кануннары һәм башка норматив хокукый актлар белән урнаштырылган, аучылык байлыкларын саклау өлкәсендә дәүләт тикшерүе чикләрендә уздырыла торган эшләргә, куела торган таләпләрне сакларга.

3. Гамәлдәге боерыкны үтәү артыннан тикшерүне үзем артыннан калдырам.

Идарә башлыгының вазифаларын үтәүче Ф.С.Батков

2014 елның 3 декабреннән
№ 190-од
Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы
объектларын саклау һәм
файдалану Идарәсе боерыгы
белән расланган

**Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендә булган урындагы затларның ( дәүләт аучылык инспекторларының) Исемлеге.**

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгының урынбасары

Хайваннар дөньясы объектларын файдалануны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә, рәткә салу, кадастр бүлеге башлыгы

Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлеге башлыгы

Кама арты зонасының хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны саклау, федераль дәүләт тикшерү һәм көйләү бүлегенең район (районара) җитәкчесе

Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны саклау, федераль дәүләт тикшерү һәм көйләү бүлегенең район (районара) башлыклары

Район( районара) хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны саклау, федераль дәүләт тикшерү һәм көйләү бүлекләренең өлкән белгечләре

Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлегенең 1 категорияле белгече